**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Ушма авыл җирлеге аерым территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^{1}$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Ушма авыл җирлегендәге Иске Завод авылының Совет урамындагы 2 йортта урнашкан шәхси йорт хуҗалыгы территориясендә һәм «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Ушма авыл җирлегендәге Иске Завод авылындагы эпизоотия чыганагыннан 1 км радиустагы территориядә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Югары Ушма авыл җирлеге аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2021 елның 27 октябрендәге ПУ-827 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы
Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 30 декабрь
№ ПУ-1019